**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора поселогы,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 13.07.2022** **№ 695**

**Башкарма комитетның «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карарының Комиссия составын раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы муниципаль максатчан программаны гамәлгә ашыру кысаларында, «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан да күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе турында» 2022 елның 16 маендагы 488 номерлы карары нигезендә, КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты алу чыгымнарының бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча субсидияләр бирү комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә.

1.2. Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты алу чыгымнарының бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә муниципаль берәмлекләр порталында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып, халыкка игълан итәргә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (икътисад буенча) М. Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның
«13»07 695 номерлы карары белән
расланды

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты алу чыгымнарының бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча субсидияләр бирү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе- Хисамутдинов Равил Фәрит улы |
| Комиссия рәисе | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты урынбасары җитәкчесе-Булгаков Мурад Рамил улы |
| Комиссия секретаре | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты икътисад бүлеге баш белгече – Адиярова Ләйсән Хәйдәр кызы |
| Комиссия әгъзалары | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары – Шакиров Әнәс Шәүкәт улы (килешү буенча) |
| | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе - Хәйретдинов Наил Фидаил улы (килешү буенча) |
| | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты икътисад бүлеге башлыгы - Нигъмәтуллина Айгөл Рәшит кызы |
| | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы - Таҗиев Илдар Илгизәр улы |
| | -Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе – Вәлиуллина Рамилә Шамил кызы |
| | Биектау муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы - Кәримов Рәхимҗан Зариф улы |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның
«13»07 695 номерлы карары белән расланды

**Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты алу чыгымнарының бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Общие положения

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыерына ия булган гражданнарга саву аппараты алу чыгымнарының бер өлешен каплауга җибәрелә торган җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану буенча субсидияләр бирү комиссиясе (алга таба – Комиссия) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы дәгъва кылучыларның саву аппараты сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга гаризаларын карау һәм хуҗалык итүче субъектларны баш санын саклап калу һәм арттыру эшләрен башкаруда стимуллаштыруга юнәлдерелгән җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында төзелде.

2. Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары

Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары түбәндәгеләр:
- Биектау муниципаль районы гражданнарының сатып алынган саву аппараты чыгымнарының бер өлешен компенсацияләүгә гаризаларын карау;
- җирле бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануны тикшереп тору.

3. Комиссиянең вәкаләтләре

Комиссиягә әлеге Нигезләмәдә каралган билгеле бер критерийлар кысаларында карарлар кабул итү вәкаләтләре бирелгән.

4. Субсидия күләмен билгеләү критерийлары

Җирле бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында каралган чаралар чикләрендә субсидияләр алучыларга түләнә.
Саву аппараты сатып алуга чыгымнар өлешен каплау күләме (субсидия күләме) 30 000 (утыз мең) сум тәшкил итә.

Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең һәр әгъзасы тарафыннан имзалана.

## 5. Йомгаклау нигезләмәсе

Комиссия эшен матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.